ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/15

Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия һәм аның бүлекләре составын раслау турында» 28/13 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасының 2011 елның 20 маендагы «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр турында» 26-ТРЗ санлы Законы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 11 декабрендәге «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия һәм аның бүлекләре составын раслау турында» 28/13 санлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия составына:

– Бәдретдинов Руслан Фәрит улын – Россия Эчке эшләр Министрлыгының Яр Чаллы шәһәре идарәсе башлыгы урынбасарын – полиция башлыгын, полиция подполковнигын (килешү буенча) кертергә;

– Козлова Лилия Рамил кызын чыгарырга;

– Вәлиева Эльвира Гафур кызының вазыйфасын яңа редакциядә бәян итәргә «Комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның Комсомол районы Хакимияте Башлыгы урынбасары»;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Үзәк районы Хакимияте карамагындагы балигъ

булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссиясе составына Хәбиров Ленар Гали улын – Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре идарәсе 3 санлы «Үзәк» полиция бүлеге башлыгы урынбасарын (килешү буенча) кертергә;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Автозавод районы Хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссиясе составына Солтанов Марат Фарафат улын – Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре идарәсе 3 санлы «Автозавод» полиция бүлеге башлыгы урынбасарын - полиция майорын (килешү буенча) кертергә;

4) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Комсомол районы Хакимияте карамагындагы балигъ булмаганнар эше һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссиясе составына Миңнеханов Рамзил Ренат улын – Россия Эчке эшләр министрлыгының Яр Чаллы шәһәре идарәсе 2 санлы «Комсомол» полиция бүлегенең участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгын (килешү буенча) кертергә.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев